КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1743

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүленгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналарга бүлү бердәм документын һәм территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүленгән җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү һәм раслау, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт төренә рөхсәтләр һәм рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектын реконструкцияләүгә рөхсәтләр бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүленгән шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүленгән территорияне планлаштыру документларын әзерләүне һәм раслауны тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының язма рәсми сораулары нигезендә «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүленгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин